ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.02.2026 133 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы муниципаль
махсуслаштырылган торак
фондыннан сәламәтлек саклау
хезмәткәрләренә хезмәт торак
урыннары бирү тәртибе турындагы
Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннарын махсуслаштырылган торак фондына һәм махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләренә кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча җитәкче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 2AE1AA8E107BD0A6911BA308E44A8D0A
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 28.01.2025 до 23.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

«___» ______ 2026 ел, №____

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә хезмәт торак урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә түбәндәге адрес буенча урнашкан торак урыннарын бирү тәртибе турында эшләнде:

Татарстан Республикасы, Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре, Землянухина урамы, 7/7 А нче йорт.

1.2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннарын махсуслаштырылган торак фондына һәм махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләренә кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары нигезендә, торак урыннан хезмәт торак урыны буларак файдалану мондый урынны, таләпләрне үтәгән килеш һәм тәртиптә махсуслаштырылган торак фондына керткәннән соң гына рөхсәт ителә. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составына һәм составыннан торак урыннарны төшереп калдыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 3 октябрендәге 1522 номерлы карары нигезендә, торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү, мондый урынны махсуслаштырылган төргә - хезмәт торак урыннарына кертеп, торак урынны күрсәтелгән торак фондыннан төшереп калдыру гамәлгә ашырыла.

1.3. Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына кертү турындагы карар Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән кабул ителә һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәүче органга мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

1.4. Әгәр торак урыннар социаль наем, дәүләт яисә муниципаль милектәге торак урынга наем, коммерциячел файдаланудагы торак фонды, аренда шартнамәләре буенча мәшгуль булса, шулай ук бу мөлкәткә хокуклары йөкләнгән булса, торак урыннарны хезмәт торак урыннарына кертү рөхсәт ителми.

1.5. Хезмәт урыннарына кертелгән торак биналар гражданнарның даими яшәве өчен яраклы булырга (билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, законнарның экологик һәм

башка таләпләренә җавап бирергә), тиешле торак пункт шартларына карата төзекләндерелергә тиеш.

1.6. Махсуслаштырылган торак фондындагы хезмәт торак урыннары гражданнарның Алабуга муниципаль районының «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – хезмәткәрләр) белән хезмәт мөнәсәбәтләре характерына бәйле рәвештә яшәү өчен каралган.

1.7. Махсуслаштырылган торак фондындагы хезмәткәрләр өчен билгеләнгән хезмәт торак урыннары Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карамагында тора.

1.8. Хезмәт торак урыннарына аерым фатирлар керә.

Торак урыннарны яллаучы берничә кеше яшәгән фатирларда бүлмәләрне хезмәт торак бүлмәсенә бүлеп бирү рөхсәт ителми. Күпфатирлы йортта хезмәт урыныннан бирелә торган торак урын буларак барлык торак урыннар да, аларның бер өлеше дә файдаланылырга мөмкин.

1.9. Торак урыннарны хезмәт торак урыннарына наем шартнамәләре буенча тапшырудан тыш, торак урыннар читләштерелергә, арендага, наемга бирелми.

1.10. Хезмәт торак урыннары Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетында исәпкә алына. Алабуга муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондының хезмәт урыннарына мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу тәртибе Алабуга муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

1.11. Хезмәт торак урыннарын наем шартнамәләре реестры Алабуга муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан алып барыла.

## 2. Хезмәт урыныннан бирелә торган торак урыннары бирү

2.1. Хезмәт торак урыннары Алабуга муниципаль районында аларның хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә эшләүче хезмәткәрләргә бирелә.

2.2. Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 12 нче йорт, 101 нче кабинет адресында урнашкан, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торак комиссиясенә «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе хезмәткәргә торак урыны бирү турындагы мәсьәләне карау өчен түбәндәге документларны тапшырыла:

1) җитәкче үтенече;

2) мөрәҗәгать итү датасын һәм аның имзасын күрсәтеп, гражданның (алга таба - мөрәҗәгать итүче) хезмәт урыны бирү турында гаризасы (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта;

3) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар (паспорт яисә аны алмаштыручы башка документлар);

4) «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән хезмәт мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар;

5) мөрәҗәгать итүчегә карата граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар (никахлашу турында таныклык, никахны өзү турында таныклык, туу турында таныклык);

6) мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары яисә аның яисә гаилә әгъзалары милкендәге торак урынның шәхси хисабыннан өземтә;

7) күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән алыш-биреш килешүләреннән мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзаларының тиешле торак пунктта (ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында) булуы турында өземтә.

2.3. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган документларны (күчермәләрне һәм төп нөсхәләрне) җитәкче тапшыра.

Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә, барлык кирәкле документларны җитәкче үтенечнамәсен тапшырган көн- документны тапшыру көне итеп санала.

2.4. Торак урын бирү йә торак урыны бирүдән баш тарту мәсьәләсе торак комиссиясе тарафыннан карала. Башкарма комитетның торак комиссиясе гаризаны мөрәҗәгать иткән көнне үк терки һәм расписка (алу кагәзе) бирә.

2.5. Әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган гариза һәм документларны карау турындагы нәтиҗәләр буенча комиссия документларны кабул иткән көннән соң 30 көн эчендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- хезмәт торак урынын бирү турында;
- хезмәт торак урыныннан бирүдән баш тарту турында.

2.6. Тиешле карар кабул ителгән көннән өч эш көне эчендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты гражданга торак урын бирү турында, хезмәт торак урыны бирүдән баш тарту турында язма рәвештә хәбәр ителә.

2.7. Түбәндәге очракларда торак урын бирүдән баш тартыла:

а) граждан тарафыннан хезмәт торак урыны бирү турында белә торып дөрес булмаган мәгълүмат тапшырса;

б) хезмәт торак урыны бирүне дәгъвалаучы гражданның йә аның гаилә әгъзаларының социаль наем шартнамәсе буенча йә ул хезмәт торак урыны бирүне дәгъвалаган Алабуга муниципаль районында урнашкан милектә бирелгән торак урыны булу;

в) хезмәт торак урыны бирү хокукын расламаган йә әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында каралган документлар тапшырылмаган яисә тулысынча документлар тапшырылмаган очракта.

2.8. Торак урыны бирү турындагы карар Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә кабул ителә һәм ул торак урынына наем шартнамәсен төзү өчен нигез булып тора.

2.9. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урынын махсуслаштырылган торак фондына һәм махсуслаштырылган торак урыннарын наем шартнамәләренә кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән расланган, хезмәт урыныннан наем шартнамәсе махсуслаштырылган торак урыннарны наем шартнамәләренең типовой формасында язма рәвештә төзелә.

Хезмәт торак урынын наем шартнамәсе предметы, хезмәт урыныннан файдалану буенча якларның хокуклары һәм бурычлары билгеләнә.

2.10. Хезмәт торак урынын наем шартнамәсе хезмәт мөнәсәбәтләре чорына бер тапкыр, әмма 5 (биш) елдан артып китмәгән чорга төзелә.

2.11. Алабуга муниципаль районы территориясендә хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату, эштән чыгару, шулай ук башка торак урынын милеккә сатып алу хезмәт торак урынын наем шартнамәсен туктату өчен нигез булып тора.

2.12. Торак урынына наем шартнамәсе яллаучы һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары торак урынына наем шартнамәсе буенча йөкләмәләрен үтәмәгән очракта, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка очракларда наемга бирүче таләбе буенча суд тәртибендә өзелергә мөмкин. Хезмәт торак урынына наем шартнамәсе мондый торак урынны югалтуга (җимерелүгә) бәйле рәвештә яисә Россия Федерациясе Торак кодексында каралган башка нигезләр нәтиҗәсендә туктатыла.

2.13. Торак урынын наем шартнамәсендә бирүче булып - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тора.

2.14. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты торак урыннары бирелгән эш бирүчедән әлеге хезмәткәрләрнең хезмәт мөнәсәбәтләрен дәвам итү яки туктату фактын раслауны таләп итәргә хокуклы.

2.15. Алабуга муниципаль районының «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесе 10 көн эчендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына торак урыны бирелгән хезмәткәр белән хезмәт мөнәсәбәтләренең туктатылуы турында язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

2.16. Бер хезмәт торак урыныннан икенчесенә үз белдеге белән күченү, шулай ук хезмәт торак урынын наем шартнамәсенә кертелмәгән затларны урнаштыру рөхсәт ителми.

2.17. Бушаган торак урыннары әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә яңадан урнаштырыла.

2.18. Торак урыннарына наем шартнамәләре өзелгән яисә туктатылган очракларда граждан һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары әлеге шартнамәләр нигезендә биләгән торак урыннарын бушатырга тиеш. Мондый торак урыннарны бушатудан баш тарткан очракта, әлеге гражданнар, Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очраклардан тыш, башка торак урыннары бирелмичә, суд тәртибендә чыгарылырга тиеш.

2.19. Россия Федерациясе Торак кодексының 103 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләре хезмәт торак урыннарыннан башка торак урыннар бирелмичә чыгарыла алмый.

## 3. Хезмәт торак урыныннан хезмәт торак урынына наем шартнамәсе буенча файдалану

Хезмәт урыны яллаучының һәм аның гаилә әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары, шулай ук наемга алучының хокуклары һәм бурычлары Алабуга

муниципаль районының махсуслаштырылган торак фондының хезмәт урыны наем шартнамәсе белән регламентлаштырыла.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан
сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә хезмәт торак
урыннары бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Гражданинга гариза бирү үрнәге
(муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыны бирүгә сорау)

Алабуга шәһәре «__» ____ 2026 ел

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына ___________ (тулы исем-фамилиясе)

Яшәү урыны буенча теркәлү адресы:______________________

Контакт телефоны: ____________________________
электрон почтасы (булса): ______________________

Шәхесне раслаучы документ (паспорт): серия ____ № ___,
бирелгән ___ (бирелү датасы), бүлек коды __________.

Гаилә хәле______________________

Гаилә составы (исем-фамилия, туган көне, туганлык дәрәҗәсе):__

Эш урыны һәм вазифасы: __________
Эш бирүченең исеме: _____________
Хезмәт килешүенең гамәлдә булу вакыты (булса): __________

Гаризаның эчтәлеге

Әлеге муниципаль районда үз торак урыны булмау һәм «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе белән хезмәт мөнәсәбәтләре булу сәбәпле, миңа (һәм югарыда күрсәтелгән гаилә әгъзаларына) Татарстан Республикасы, Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре, Землянухина урамы, 7/7 А нче йорт адресында урнашкан, муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан хезмәт торак урыны бирүегезне сорыйм.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Теркәлгән документлар исемлеге (күчермәләр, төп нөсхәләр күрсәтелә):

Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчесенең үтенече.

Паспорт күчермәсе (һәм гаризада күрсәтелгән гаилә әгъзаларының паспортлары).

Эшкә урнашу турында белешмә (хезмәт килешүе, эш урыныннан белешмә).

Гражданлык хәле актларын теркәү турында таныклыклар (никах, балалар туу, аерылышу — булган очракта).

Мөрәҗәгать итүче фактта биләгән торак урынның шәхси счетыннан өземтә (булган очракта).

Мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары милкендә Алабуга шәһәрендә торак урын булу (яисә булмау) турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә.

Гариза бирүченең имзасы: (фамилиясе, исеме, атасының исеме)_______.

Искәрмә: гариза язмача рәвештә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торак комиссиясенә түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Алабуга шәһәре, Мир проспекты, 12 нче йорт, 101 нче кабинет.

Гариза тапшырганнан соң, документлар кабул ителү турында расписка (алу кәгазе) бирелә.

Лист согласования к документу № 133 от 04.02.2026
Инициатор согласования: Шарифуллина З.Р. Секретарь
Согласование инициировано: 05.02.2026 09:40

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 05.02.2026 - 11:41 | - |